**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# О внесении изменений в Положение об организации и ведении гражданской обороны в Республике Татарстан

В связи с изменениями в федеральном законодательстве в области гражданской обороны **постановляю**:

1. Внести в Положение об организации и ведении гражданской обороны в Республике Татарстан, утвержденное Указом Президента Республики Татарстан от 22 ноября 2008 года № УП-598 «Об утверждении Положения об организации и ведении гражданской обороны в Республике Татарстан» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 17 октября 2014 года № УП-995, от 19 января 2016 года № УП-18 и от 4 июня 2016 года № УП-502), следующие изменения:

а) в пункте 1.3 слова «Органы исполнительной власти Республики Татарстан» заменить словами «Органы государственной власти Республики Татарстан»;

б) пункт 1.4 признать утратившим силу;

в) в пункте 2.3:

в абзаце четвертом слово «целевые» заменить словом «государственные»;

абзац седьмой изложить в следующей редакции:

«определяет перечень организаций, обеспечивающих выполнение мероприятий республиканского уровня по гражданской обороне;»;

г) в пункте 2.5:

в абзаце первом слова «(далее – МЧС Республики Татарстан)» исключить;

в абзаце четвертом слова «целевых программ» заменить словами «государственных программ Республики Татарстан»;

д) в абзаце третьем пункта 2.7 слова «целевых программ» заменить словами «государственных программ Республики Татарстан»;

е) в пункте 2.8 слово «действующим» исключить;

ж) абзац третий пункта 3.2 изложить в следующей редакции:

«создание и поддержание в состоянии готовности локальных систем оповещения организациями, эксплуатирующими опасные производственные объекты I и II классов опасности, особо радиационно опасные и ядерно опасные производства и объекты, последствия аварий на которых могут причинять вред жизни и здоровью населения, проживающего или

осуществляющего хозяйственную деятельность в зонах воздействия поражающих факторов за пределами их территорий, гидротехнические сооружения чрезвычайно высокой опасности и гидротехнические сооружения высокой опасности;»;

з) в пункте 3.4:

абзац второй после слова «строительство,» дополнить словом «сохранение,»;

абзац пятый дополнить словами «, в заглубленных помещениях и других сооружениях подземного пространства»;

и) в абзаце втором пункта 3.5 слова «и организациями, обеспечивающими выполнение мероприятий по гражданской обороне,» исключить;

к) в абзаце втором пункта 3.6 слова «и спасательных служб (служб гражданской обороны)» заменить словами «, спасательных служб и единой государственной системы предупреждения и ликвидации чрезвычайных ситуаций»;

л) абзац второй пункта 3.9 изложить в следующей редакции:

«создание и обеспечение готовности сети наблюдения и лабораторного контроля гражданской обороны и защиты населения – действующих специализированных учреждений, подразделений и служб органов государственной власти Республики Татарстан и организаций, осуществляющих функции наблюдения и контроля за радиационной, химической, биологической обстановкой на территории Республики Татарстан;»;

м) в абзаце втором пункта 3.12 слова «, разработка планов» заменить словами «и планирование»;

н) пункт 4.1 изложить в следующей редакции:

«4.1. Руководителем гражданской обороны в Республике Татарстан является Президент Республики Татарстан, который осуществляет руководство гражданской обороной в Республике Татарстан через территориальный орган федерального органа исполнительной власти, уполномоченный решать задачи гражданской обороны и задачи по предупреждению и ликвидации чрезвычайных ситуаций, – Главное управление МЧС России по Республике Татарстан.»;

о) в пункте 4.2 слова «Заместителем руководителя гражданской обороны Республики Татарстан является первый заместитель Премьер-министра Республики Татарстан (один из первых заместителей Премьер-министра Республики Татарстан)» заменить словами «Заместителем руководителя гражданской обороны в Республике Татарстан является Премьер-министр Республики Татарстан»;

п) пункт 4.3 признать утратившим силу;

р) в пункте 4.4 слова «в органах местного самоуправления осуществляют главы» заменить словами «на территориях муниципальных образований осуществляют руководители исполнительных комитетов»;

с) пункт 4.6 изложить в следующей редакции:

«4.6. В целях организации и ведения гражданской обороны руководители (заместители руководителя) гражданской обороны соответствующих уровней издают приказы и распоряжения.

Приказы и распоряжения руководителей (заместителей руководителя) гражданской обороны, изданные в пределах их компетенции в области гражданской обороны, обязательны для исполнения всеми должностными лицами и гражданами.»;

т) в пункте 4.7 слова «(служб гражданской обороны)» исключить;

у) пункт 4.8 изложить в следующей редакции:

«4.8. Органами, осуществляющими управление гражданской обороной на территории Республики Татарстан, являются:

федеральный орган исполнительной власти, уполномоченный на решение задач в области гражданской обороны на территории Республики Татарстан;

территориальный орган – орган, уполномоченный решать задачи гражданской обороны и задачи по предупреждению и ликвидации чрезвычайных ситуаций по Республике Татарстан;

структурные подразделения федеральных органов исполнительной власти и органов местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан, уполномоченные на решение задач в сфере гражданской обороны;

структурные подразделения (работники) организаций, уполномоченные на решение задач в области гражданской обороны, создаваемые (назначаемые) в порядке, установленном Правительством Российской Федерации.»;

ф) пункт 4.11 изложить в следующей редакции:

«4.11. Для решения задач в области гражданской обороны, реализуемых на территории Республики Татарстан, создаются силы гражданской обороны. В состав сил гражданской обороны Республики Татарстан входят подразделения противопожарной службы Республики Татарстан, аварийно-спасательные формирования и спасательные службы, нештатные формирования по обеспечению выполнения мероприятий по гражданской обороне.»;

х) в пункте 4.12:

в абзаце первом слова «(служб гражданской обороны)» исключить;

абзацы четвертый – шестой признать утратившими силу;

ц) пункт 4.13 изложить в следующей редакции:

«4.13. Организации, отнесенные в установленном порядке к категориям по гражданской обороне, создают и поддерживают в состоянии готовности нештатные формирования по обеспечению выполнения мероприятий по гражданской обороне.

Организации, эксплуатирующие опасные производственные объекты I и II классов опасности, особо радиационно опасные и ядерно опасные производства и объекты, гидротехнические сооружения чрезвычайно высокой опасности и гидротехнические сооружения высокой опасности,

за исключением организаций, не имеющих мобилизационных заданий (заказов) и не входящих в перечень организаций, обеспечивающих выполнение мероприятий по гражданской обороне федерального органа исполнительной власти, и организаций, обеспечивающих выполнение мероприятий регионального и местного уровней по гражданской обороне, создают и поддерживают в состоянии готовности нештатные аварийно-спасательные формирования.

Организации, эксплуатирующие опасные производственные объекты I и II классов опасности, особо радиационно опасные и ядерно опасные производства и объекты, последствия аварий на которых могут причинять вред жизни и здоровью населения, проживающего или осуществляющего хозяйственную деятельность в зонах воздействия поражающих факторов за пределами их территорий, гидротехнические сооружения чрезвычайно высокой опасности и гидротехнические сооружения высокой опасности, создают и поддерживают в состоянии готовности локальные системы оповещения.»;

ч) пункт 4.14 признать утратившим силу;

ш) в пункте 4.15 слова «(служб гражданской обороны)» исключить;

щ) в абзаце втором пункта 4.18 слова «органами исполнительной власти Республики Татарстан» заменить словами «органами государственной власти Республики Татарстан»;

э) пункт 4.19 изложить в следующей редакции:

«4.19. Обеспечение координации деятельности органов управления гражданской обороной, управления силами и средствами гражданской обороны, организации информационного взаимодействия территориальных органов федеральных органов исполнительной власти, органов государственной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления и организаций при решении задач в области гражданской обороны, а также при осуществлении мер информационной поддержки принятия решений в области гражданской обороны в соответствии с федеральным законодательством осуществляет центр управления в кризисных ситуациях Главного управления МЧС России по Республике Татарстан.»;

ю) пункт 5.3 дополнить словами «природного и техногенного характера в военное время».

2. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
27 января 2020 года
№ УП-27

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Гражданнар оборонасы өлкәсендә федераль законнарга үзгәрешләр кертелү белән бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-598 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 17 октябрендәге ПУ-995 номерлы, 2016 елның 19 гыйнварындагы ПУ-18 номерлы һәм 2016 елның 4 июнендәге ПУ-502 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 1.3 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1.4 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

в) 2.3 пунктта:

дүртенче абзацта «максатчан» сүзен «дәүләт» сүзенә алмаштырырга;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданнар оборонасы буенча республика дәрәҗәсендә уздырыла торган чаралар үтәлешен тәэмин итүче оешмалар исемлеген билгели;»;

г) 2.5 пунктта:

беренче абзацта «(алга таба – Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы)» сүзләрен төшереп калдырырга;

дүртенче абзацта «максатчан программалар» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт программалары» сүзләренә алмаштырырга;

д) 2.7 пунктның өченче абзацында «максатчан программалар» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт программалары» сүзләренә алмаштырырга;

е) 2.8 пунктта «гамәлдәге» сүзен төшереп калдырырга;

ж) 3.2 пунктта өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«алардагы һәлакәт нәтиҗәләре һәлакәтле факторлар йогынты ясый торган зоналарда яшәүче яисә хуҗалык эшчәнлеге алып баручы халыкның гомеренә һәм сәламәтлегенә зыян салуы мөмкин булган I һәм II куркынычлык классына кергән куркынычлы җитештерү объектларын, радиацияле аеруча

куркынычлы һәм атом-төш куркынычлы производстволар һәм объектлар, куркынычлыгы гадәттән тыш югары гидротехник корылмаларны һәм куркынычлыгы югары гидротехник корылмаларны эксплуатацияли торган оешмалар локаль хәбәр итү системаларын булдыра һәм аларны әзерлек хәлендә тотуны тәэмин итә;»;

з) 3.4 пунктта:

икенче абзацта «төзелеш,» сүзеннән соң «саклау,» сүзен өстәргә;

бишенче абзацта «, чокырсыман биналарда һәм җир асты мәйданчыкларындагы башка корылмаларда» сүзләрен өстәргә;

и) 3.5 пунктның икенче абзацында «һәм граждан оборонасы буенча чараларны үтәүне тәэмин итә торган оешмалар,» сүзләрен төшереп калдырырга;

к) 3.6 пунктның икенче абзацында «һәм коткару хезмәтләре (граждан оборонасы хезмәтләре)» сүзләрен «, коткару хезмәтләре һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү бердәм дәүләт системасы» сүзләренә алмаштырырга;

л) 3.9 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гамәлдәге махсуслаштырылган учреждениеләр, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының бүлекчәләре һәм хезмәтләре һәм Татарстан Республикасы территориясендә радиациягә, химиягә, биологиягә бәйле хәлне күзәтеп тору һәм контрольдә тоту функцияләрен башкаручы оешмалар – гражданнар оборонасы һәм халыкны яклау күзәтчелек һәм лаборатор анализ челтәрен булдыру һәм аның әзерлеген тәэмин итү;»;

м) 3.12 пунктның икенче абзацында «, планнар эшләү» сүзләрен «һәм планлаштыру» сүзләренә алмаштырырга;

н) 4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы җитәкчесе Татарстан Республикасы Президенты була, ул Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы белән җитәкчелек итүне федераль башкарма хакимият органының территориаль органы – гражданнар оборонасы бурычларын һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү бурычларын хәл итәргә вәкаләтле орган – Россия Федерациясе Граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларның нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе аша башкара.»;

о) 4.2 пунктта «Татарстан Республикасы граждан оборонасы җитәкчесенең урынбасары Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары (Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасарларының берсе) була» сүзләрен «Татарстан Республикасының гражданнар оборонасы җитәкчесе урынбасары Татарстан Республикасы Премьер-министры була» сүзләренә алмаштырырга;

п) 4.3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

р) 4.4 пунктта «Җирле үзидарә органнарында граждан оборонасы белән муниципаль берәмлекләр башлыклары җитәкчелек итә» сүзләрен «Муниципаль берәмлекләр территорияләрендә граждан оборонасы белән

башкарма комитетлар җитәкчеләре җитәкчелек итә» сүзләренә алмаштырырга;

с) 4.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.6. Гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару максатларында тиешле дәрәҗәләрдәге гражданнар оборонасы җитәкчеләре (җитәкчесе урынбасарлары) боерыклар һәм күрсәтмәләр чыгара.

Гражданнар оборонасы өлкәсендә гражданнар оборонасы җитәкчеләренең (җитәкчесе урынбасарларының) үз компетенциясе чикләрендә чыгарган боерыклары һәм күрсәтмәләре барлык вазыйфаи затлар һәм гражданнар тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиеш.»;

т) 4.7 пунктта «(гражданнар оборонасы хезмәтләре)» сүзләрен төшереп калдырырга;

у) 4.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.8. Татарстан Республикасы территориясендә гражданнар оборонасы белән идарә итүне гамәлгә ашыручы органнар түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасы территориясендә гражданнар оборонасы өлкәсендә бурычларны хәл итүгә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы;

территориаль орган – Татарстан Республикасы буенча гражданнар оборонасы бурычларын һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бурычларны хәл итүгә вәкаләтле орган;

федераль башкарма хакимият органнарының һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең гражданнар оборонасы өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә вәкаләтле җирле үзидарә органнарының структур бүлекчәләре;

гражданнар оборонасы өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә вәкаләтле, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләгән тәртиптә оештырыла (билгеләнә) торган оешмаларның структур бүлекчәләре (хезмәткәрләре).»;

ф) 4.11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.11. Татарстан Республикасы территориясендә гражданнар оборонасы өлкәсендә гамәлгә ашырыла торган бурычларны хәл итү өчен гражданнар оборонасы көчләре булдырыла. Татарстан Республикасының гражданнар оборонасы көчләре составына Татарстан Республикасының янгынга каршы хезмәт бүлекләре, һәлакәттән коткару формированиеләре һәм коткару хезмәтләре, гражданнар оборонасы буенча чараларның үтәлешен тәэмин итү буенча штаттан тыш формированиеләр керә.»;

х) 4.12 пунктта:

беренче абзацта «(гражданнар оборонасы хезмәтләре)» сүзләрен төшереп калдырырга;

дүртенче – алтынчы абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

ц) 4.13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.13. Гражданнар оборонасы категорияләренә билгеләнгән тәртиптә кертелгән оешмалар гражданнар оборонасы чараларының үтәлешен тәэмин итү буенча штаттан тыш формированиеләр төзи һәм аларның әзер хәлдә булуын тәэмин итә.

I һәм II куркынычлык классларындагы куркыныч җитештерү объектларын, радиацияле аеруча куркыныч һәм атом-төш куркынычлы

производстволарны һәм объектларны, куркынычлыгы гадәттән тыш югары гидротехник корылмаларны һәм куркынычлыгы югары гидротехник корылмаларны эксплуатацияли торган оешмалар (мобилизация йөкләмәләре (заказлары) булмаган һәм федераль башкарма хакимият органының гражданнар оборонасы буенча чараларның үтәлешен тәэмин итүче оешмалар һәм гражданнар оборонасы буенча төбәк һәм җирле дәрәҗәләрдәге чараларның үтәлешен тәэмин итүче оешмалар исемлегенә кермәгән оешмалардан тыш) һәлакәттән коткару буенча штаттан тыш формированиеләрен төзи һәм аларның әзерлек хәлендә булуын тәэмин итә.

Алардагы һәлакәт нәтиҗәләре һәлакәтле факторлар йогынты ясый торган зоналарда яшәүче яисә хуҗалык эшчәнлеге алып баручы халыкның гомеренә һәм сәламәтлегенә зыян салуы мөмкин булган I һәм II куркынычлык классына кергән куркынычлы җитештерү объектларын, радиацияле аеруча куркынычлы һәм атом-төш куркынычлы производстволар һәм объектлар, куркынычлыгы гадәттән тыш югары гидротехник корылмаларны һәм куркынычлыгы югары гидротехник корылмаларны эксплуатацияли торган оешмалар локаль хәбәр итү системаларын булдыра һәм аларны әзерлек хәлендә тотуны тәэмин итә.»;

ч) 4.14 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

ш) 4.15 пунктта «(гражданнар оборонасы хезмәтләре)» сүзләрен төшереп калдырырга;

щ) 4.18 пункттагы икенче абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары» сүзләренә алмаштырырга;

э) 4.19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.19. Гражданнар оборонасы белән идарә итү, гражданнар оборонасы көчләре һәм чаралары белән идарә итү органнары эшчәнлеген координацияләүне, гражданнар оборонасы өлкәсендә бурычларны хәл иткәндә, шулай ук гражданнар оборонасы өлкәсендә федераль законнар нигезендә карарлар кабул итүгә мәгълүмати ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашырганда федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмаларның мәгълүмати хезмәттәшлеген оештыруны тәэмин итүне Россия Федерациясе Граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе кризислы хәлләрдә идарә үзәге гамәлгә ашыра.»;

ю) 5.3 пунктка «сугыш вакытында табигый һәм техноген характердагы» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2020 ел, 27 гыйнвар
№ ПУ-27

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН *
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ